# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Мадык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**04.12. 2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Мадык торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 04 декабрендә 08:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Мадык торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1.Мадык торак пунктында Киров урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм җәю);

2. Мадык торак пунктында урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтү, ремонтлау, лампаларны һәм фонарьларны алыштыру. Килешү буенча түләү;

3.Мадык торак пунктында халыкны су белән тәэмин итү (ремонтлау, хезмәт күрсәтү, тирәнлек насослары, колонкалар һәм башка материаллар сатып алу);

4.Мадык торак пунктында урамнарны кардан чистарту (дизель, ягулык һәм майлар сатып алу).

5. Янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм ремонтлау. Янгын сүндерү машинасы шоферына килешү буенча түләү

6. Мадык торак пунктында бензин триммеры (моточапкыч) һәм төзекләндерү өчен тагылмалар сатып алу. Килешү буенча түләү.

7.МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү. Тракторчы килешүе буенча хезмәт хакы.

8.Гаражны агымдагы ремонтлау өчен материаллар сатып алу.

9.Мадык торак пунктында үлән һәм чүп үләннәрен чабу. (дизель, ягулык һәм майлар сатып алу).

10.Мәйдан бизәү өчен материаллар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 39 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 22 кеше, бу 56 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларнын тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 22 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Мадык торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Мадык торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1.Мадык торак пунктында Киров урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм җәю);

2. Мадык торак пунктында урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтү, ремонтлау, лампаларны һәм фонарьларны алыштыру. Килешү буенча түләү;

3.Мадык торак пунктында халыкны су белән тәэмин итү (ремонтлау, хезмәт күрсәтү, тирәнлек насослары, колонкалар һәм башка материаллар сатып алу);

4.Мадык торак пунктында урамнарны кардан чистарту (дизель, ягулык һәм майлар сатып алу).

5. Янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм ремонтлау. Янгын сүндерү машинасы шоферына килешү буенча түләү

6. Мадык торак пунктында бензин триммеры (моточапкыч) һәм төзекләндерү өчен тагылмалар сатып алу. Килешү буенча түләү.

7.МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү. Тракторчы килешүе буенча хезмәт хакы.

8.Гаражны агымдагы ремонтлау өчен материаллар сатып алу.

9.Мадык торак пунктында үлән һәм чүп үләннәрен чабу. (дизель, ягулык һәм майлар сатып алу).

10.Мәйдан бизәү өчен материаллар сатып алу.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

(https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукы мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы
Э.И.Михайлов